КАБУЛ ИТҮ

# Берсе дә игътибарсыз калмый



“Бердәм Россия” сәяси партиясенең Зәй җирле бүлеге кабул итү пунктында район башлыгы, партиянең җирле бүлеге секретаре Разиф Кәримов халыкны шәхси сораулары буенча кабул итте. Анда зәйлеләр район җитәкчесенә үзен борчыган сораулар белән килгән иде. Мөрәҗәгать итүчеләр арасында яшәү урыны буенча проблемалары булучылар да, үзе яшәгән күпкатлы йортны капиталь төзекләндерү программасына кертүне сораучы, Мирный, Икмәк кабул итү микрорайоннарындагы кайбер урамнарда юллар төзексезлегеннән зарланучылар да, урамнарның яктыртылышы буенча да, газ үткәрү мәсьәләсен күтәреп тә һәм башка күп сораулар белән килүчеләр булды. Араларыннан Иманлебаш авылыннан Миннезәкия апа Габдрахимова йортлары яну сәбәпле ярдәм оештыруны сорап килгән.

- Апрель аенда йорт янды. Хәзер аны яңадан сафка бастыру өчен күп чыгым кирәк. Туганнар, балалар ярдәменнән ташламый анысы, шулай да өстәмә ярдәм булса, җиңелрәк булыр иде. Безгә социаль яклау идарәсе, Дәүләт Думасы, Дәүләт Советы депутатларыннан, районнан берәз булыштылар, әмма әле йортыбыз түбәсез, - ди Миннезәкия апа.

Аларның йортлары иминиятләнмәгән булган, шуңа бик кыен хәлдә калганнар. Район башлыгы янгыннан зыян күрүчеләргә законда каралган ярдәмне ясыйбыз, әгәр дә өлкән яшьтәге апаны балалары, туганнары үз канаты астына алмаса, без аңа билгеле вакытка торак урын бирергә бурычлыбыз, дип ассызыклады.

Кабул итү вакытында кергән һәр сорау аерым контрольгә алынды.

БУ МӨҺИМ

# Укыту, семинар узды

**Шәһәр, район территориаль һәм участок сайлау комиссияләре әгъзалары өчен өйрәнү семинары уздырылды.**

Әлеге семинар-киңәшмәне республика район-шәһәрләре буйлап Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе үткәрә. Мондый укулар агымдагы елның 23 маенда башланган булган, ул якын көннәрдә тәмамланыр дип көтелә. Киңәшмә алдыннан район башлыгы Разиф Кәримов һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Әгъзам Гобәйдуллин шәһәр һәм район территориаль участок сайлау комиссияләре составы белән очраштры, аннан хакимиятнең зур залында җыелган шәһәр, район территориаль һәм участок сайлау комиссияләре әгъзалары белән сөйләште. Өйрәтү программасы исә сайлау комиссияләренең эшчәнлегенә кагылышлы актуаль мәсьәләләрне үз эченә алган. Республика Үзәк сайлау комиссиясе рәисе секретаре Надежда Борисова сайлау законнарындагы үзгәрешләр, сайлау участокларындагы ситуацияләр турында мәгълүматны җиткереп, бик үтемле һәм җентекле итеп участок сайлау комиссияләренең вәкаләтләре, сайлаучыларга информация ясау һәм сайлау алды агитациясе кагыйдәләрен үтәүдә күзәтчелек итү буенча алып барылган эш турында сөйләде, сорауларга җавап бирде. «Мин сайлау системасындагы үзгәрешләрне нормаль дип саныйм, сайлау системасы яшь, камилләшү таләп итә. Үзгәрешләр, беренче чиратта, сайлау процедурасында үтә күренмәлелеккә юнәлдерелгән, – диде Әгъзам Гобәйдуллин, журналистларга биргән әңгәмәсендә.



АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕНДӘ

# Сусызлыкка чик куелды

**Дөньяда да, тормышта да иң кирәкле әйберләрнең берсе - су. Ул - тереклек һәм яшәү чыганагы.**

Чыбыклы авылы Тукай урамында яшәүчеләр сусызлык проблемасыннан иза чигеп яшәде. Моннан 20-30 ел элек салынган торбалар тәмам тузып, череп, хәтта уалып беткән була. Иске торбаның яраксызлыгы, еш тишелеп торуы нәтиҗәсендә бирегә кыш көне дә өзеклекләр булгалый. Сусызлык проблемасы бу елда хәл ителә. «Теплосервис» җаваплылыгы чикләнгән ширкәте бирегә торбалар алыштыруны башкарды.

Ширкәт эшчеләре Чыбыклыда проблемалы булган 70 метр араны казып, 65 сантиметр диаметрлы калын торба салдылар. Бу эш шактый катлаулы шартларда барды, өстән яңгыр яуганда да эшчеләр туктамый. Шул рәвешле оешмадан су торбалары алыштыру белән 3 кеше хезмәт куя. Үз эшенең остасы булган Илсур Насыйров экскаваторы белән җир казу эшен башкара. Канауда торба ялгау катлаулы эшләрдән санала, эретеп ябыштыручы Николай Соловьев исә балчык ишелгән урыннарны көрәк белән өскә атып та тора. Резин итекләр эче су белән тулса да торба ялгауны дәвам иттек, эшне җиренә җиткереп башкардык, диләр ширкәт эшчеләре.

-Җитмәсә казыган канауга иске торба эчендәге су агып чыгып, хәлне тагын да катлауландырды, егетләр ничек итсә итте, сууткәргечләрне өлешчә яңартты, - ди ширкәт директоры Рәйхат Гарипов.

Тукай урамында торбаны узган ел көз алыштыра башлаган булганнар, тик көннәр кинәт суытып, эш ярты юлда бүленеп калган. “Теплосервис” ширкәте эшне хәзер тиз һәм сыйфатлы итеп башкарды. Бүгенге көндә әлеге урам халкы, ниһаять, бу борчыган проблемадан азат булды.”Теплосервис” оешмасы җәйләрен дә суга кытлык булмас дип ышандыра. Чыбыклыларның сулы булганга ышанасы да килми хәтта. Алга таба авылның Вахитов урамында да, Сәвәләй, Аксар авылларында да торба алыштыру белән бәйле казу эшләре планлаштырыла.

Хәзергесе көндә ширкәт Поповка авылында республика программасы буенча сафка басучы клуб тирәсен төзекләндерү эшләре белән мәшгуль.

***Рәзимә* КАШАПОВА.**



СОРАУ-ҖАВАП

# Сатучы түгел, сатып алучы хәл итә



***“Әбигә телефон аппараты сатып алган идек. Ярты ел гына эшләде дә, ватылды. Гарантия буенча каралган ремонтка бирдек. Аны ремотлаганда башка аппарат биреп тордылар, анысы да эшләми башлады. Телефонны ремонтлау ике ай ярымга сузылды. Шуңа күрә башка бер кибеттән яңа телефон аппараты сатып алырга туры килде. Беренче аппаратны алган кибеткә барып акчаны кире кайтаруларын сорагач, акча кире кайтарылмый, бездән яңа аппарат сатып алыгыз, дип җавап бирделәр. Бу дөресме?” Антон.***

Сорауга Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясенең үсеш һәм эчке базарны координацияләү бүлеге консультанты **Алина НАСЫЙРОВА** җавап бирә:

*-“Кулланучылар хокукларын яклау турында” Закон нигезендә товарның кимчелеген бетерү (төзәтү) яклар арасындагы язмача килешүдә күрсәтелмәгән очракта, кимчелекләр товарны җитештерүче (оешма яисә шәхси эшмәкәр вәкаләте алган сатучы) тарафыннан кичекмәстән хәл ителергә тиеш. Яклар арасындагы язмача килешүдә кимчелекне хәл итү срогы кырык биш көннән артмаска тиеш. Законның 23нче маддәсе нигезендә мәсьәләне хәл итү билгеләнгән срокларда үтәлмәгән очракта, кулланучы (сатып алучы) үзе сайлап, башка таләпләр куюга хокуклы, ягъни товарны алмаштыру яисә аның акчасын кире алуны сатучы түгел, ә сатып алучы хәл итә. Шунысын да әйтергә кирәк, сатып алучы тарафыннан товарны алмаштыру яисә аның акчасын кире алу таләп куелганнан соң ун көн эчендә хәл ителергә тиеш.*